ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
НОВОСПАССКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ЗАИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ул. Молодежная, д. 13, с. Новоспасск, 423535

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗӘЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ЯҢА СПАС АВЫЛ ҖИРЛЕГЕНЕҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Яшьләр урамы, 13 нче йорт,
Яңа Спас авылы, Зәй районы, 423535

Телефон: 6-45-48. Электронный адрес: Nspas.Zai@tatar.ru , сайт: https://zainsk.tatarstan.ru/novospasskoe.htm

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**Яңа Спас авылы**

**04.08.2026** **№ 11**

**«Яңа Спас авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең торак пунктлары чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларының сакланышын тәэмин итүгә муниципаль контрольне гамәлгә ашыру буенча административ регламентны раслау турында» 20.03.2012 №3 Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының Яңа Спас авыл җирлеге башкарма комитеты карарының үз көчен югалтуын тану хакында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Зәй муниципаль районының Яңа Спас авыл җирлеге Уставына, Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының Яңа Спас авыл җирлеге башкарма комитетына таянып

**карар итте:**

1. «Яңа Спас авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең торак пунктлары чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларының сакланышын тәэмин итүгә муниципаль контрольне гамәлгә ашыру буенча административ регламентны раслау турында» 20.03.2012 №3 Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Яңа Спас авыл җирлеге башкарма комитеты карарын үз көчен югалткан дип танырга.
2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (PRAVO.TATARSTAN.RU), җирлекнең торак пунктлары территориясендә махсус мәгълүмат стендларында бастырып чыгарырга һәм Зәй муниципаль районының рәсми сайтында «Авыл җирлекләре» бүлегендә урнаштырырга.
3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.
4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үземдә калдырам.

Башкарма комитет җитәкчесе Танчук Н.В.